СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

17.09.2019 | с. Набережные Моркваши | 79-340

**Яр Буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 12.09.2019 ел, № 78-337 карары, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 12.09.2009 ел, № 14 карары нигезендә,

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Яр буе Морквашы авыл җирлеге**
**карар чыгарды:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?:

- Яр буе Морквашы, Лесные Моркваши, Покровка авылларында юлларны ремонтлау;
- Никольский бистәсендә чишмәләрне төзекләндерү;
- Покровка авылында һәм Пустые Моркваши бистәсендә балалар мәйданчыгына инвентарь сатып алу.

**ӘЙЕ ЮК»**

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Яр буе Морквашы авыл җирлеге**
**Башлыгы И.Х.Гаязов**